КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 19 июль г.Казань № 601

«Урта һөнәри белем бирү буенча мәгариф программаларын – урта звено белгечләрен әзерләү программаларын тормышка ашыру» дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын раслау турында

Дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең сыйфатын яхшырту, алардан халыкның барлык катламнары файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итү һәм дәүләт хезмәтләре күрсәтүче оешмаларга карата таләпләрне стандартлаштыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән «Урта һөнәри белем бирү буенча мәгариф программаларын – урта звено белгечләрен әзерләү программаларын тормышка ашыру» дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын расларга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип санарга:

«Урта һөнәр белеме бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандарты турында» 2010 ел, 13 июль, 555 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Урта һөнәр белеме бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандарты турында» 2010 ел, 13 июль, 555 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 ел, 15 март, 159 нчы;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Урта һөнәр белеме бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандарты турында» 2010 ел, 13 июль, 555 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 ел, 30 октябрь, 820 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2011 ел, 12 октябрь, 846 нчы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарының 1 нче пункты.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин